## АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 35 01 февраль 2017 ел

**"Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**"Мюд авыл җирлеге»муниципаль берәмлек Уставына**
**үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына 1 нче кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен Юстиция органына җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелгәннән соң махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге Советы Рәисе Н.В.Бокарева

Кушымта № 1

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге
Совет карарына
01.02.2017ел № 35

**"Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**"Мюд авыл җирлеге»муниципаль берәмлек Уставына**
**үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"**

**1. 7 статьяны 15 пункт белән өстәргә) киләсе редакциядә:**

«15) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында"2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру.

**2. 47 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә абзац белән тулыландырырга:**

« - "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында"2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру.